ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә
алып барыла торган эш турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә алып барыла торган эш турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.А. Зарипова, Татарстан Республикасы Мәдәният министры И.Х. Әюпова һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы М.Ш. Галиев мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә алып барыла торган эш турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.А. Зарипова, Татарстан Республикасы Мәдәният министры И.Х. Әюпова һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы М.Ш. Галиев мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына миграция законнарын гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына сайлау округлары территорияләрендә чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү мәсьәләләрен хәл итүдә катнашырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы утырышында «хөкүмәт сәгате» кысаларында яңгыраган сорауларны хәл итү һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча өстәмә чаралар күрергә.

4.2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты белән берлектә эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә

матди ярдәм күрсәтү мөмкинлеген закон дәрәҗәсендә беркетү мәсьәләсен эшләргә.

4.3. Татарстан Республикасының гавами хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасында этникара һәм динара мөнәсәбәтләрне гармонияләүгә, чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

4.4. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә миграция законнары мәсьәләләре буенча мәгълүмати материаллар әзерләүне һәм нәшер итүне дәвам итәргә, аларны актуальләштерүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Татарстан Республикасында миграция вәзгыятен тикшереп тору өлешендә, шул исәптән законсыз миграциягә һәм чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында җинаятьчелеккә каршы көрәш максатларында, эшне дәвам итәргә.

5.2. Чит ил гражданнарын ялган миграция исәбенә кую фактларын һәм миграция законнары таләпләрен үтәмәүнең башка фактларын ачыклау эшен дәвам итәргә.

5.3. Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә тоту шартларын анализларга.

5.4. «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында республиканың башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлектә чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни адаптациясенә ярдәм итү максатларында алар белән мәгълүмати һәм оештыру-методик эшне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хезмәт базары торышын һәм Татарстан Республикасында 2025 елда чит ил эшчеләрен җәлеп итүгә квота артуга бәйле рәвештә эшче көчләргә чынбарлыктагы ихтыяҗны мониторинглау эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

8. Татарстан халыклары Ассамблеясына Татарстан Республикасындагы милли диаспоралар вәкилләре белән Татарстан Республикасында килеп чыгу куркынычы булган милләтара низагларны кисәтүгә, чит ил гражданнарының хокук бозуларын профилактикалауга, этникара һәм динара мөнәсәбәтләрне

нығыту өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән эшне активлаштыруны тәкъдим итәргә.

9. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

9.1. «Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсын үткәрүне дәвам итәргә.

9.2. Чит ил гражданнарына Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре, террористик юнәлештәге җинаятьләрне әзерләүнең яисә кылуның билгеле булган фактлары турында хокук саклау органнарына хәбәр итү ысуллары хакында, террористик һәм башка деструктив эшчәнлектә катнашкан һәм аңа ярдәм иткән өчен җаваплылык турында җиткерү максатларында «Татарстан Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе телеграм каналларын популярлаштыруга ярдәм итәргә.

10. 2025 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына әлеге карарның 3 – 9 пунктларын үтәү барышы турында мәгълүмат җибәрергә.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 176-VII ДС